РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЛОБУИНКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАТАР БУАСЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

23 январь 2023 ел

№ 3

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Татар Буасы авыл җирлеге башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 февраленнән Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 7793,48 суммасында 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 3 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» карарын үз көчен 2023 елның 1 февраленнән югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының Татар Буасы
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Йосыпов

Буа муниципаль районы
Татар Буасы авыл җирлеге
башкарма комитетының
23.01.2023 елның № 3 карарына
1 кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлегендә 01.02.2023 елдан җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле
БӘЯЛӘРЕ

| № т/б | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 00,00 |
| 2. | Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү. | 5520,90 |
| 3. | Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 783,24 |
| 4. | Күмү (кабер казу һәм күмү) | 1486,34 |
| | Барлыгы | 7793,48 |

Буа муниципаль районы
Татар Буасы авыл җирлеге
башкарма комитетының
23.01.2023 елның № 3 карарына
2 кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлегендә
01.02.2023 елдан җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле
БӘЯЛӘРЕ

| № т/б | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 00,00 |
| 2. | Җәсәдләү | 2758,9 |
| 3. | Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү. | 2758,9 |
| 4. | Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 778,6 |
| 5. | Күмү (кабер казу һәм күмү ) | 1497,08 |
| Барлыгы | | 7793,48 |